ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2023 елның 13 октябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 11.10.2023 елның 13.00 сәгатендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында узган гражданнар Җыенының йомгак беркетмәсе төзелде:«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучы Россия Федерациясе Кораллы көчләре хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1 төркем инвалидлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Горшково авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- халыкның күпләп ял итү урыннарын (паркларны, скверларны, яр буен, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннарны) төзекләндерү һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү;

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү» белән килешәсезме?

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 105 кеше кертелгән, 64 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен - гражданнар җыенында катнашкан 64 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында гражданнар җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучы Россия Федерациясе Кораллы көчләре хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1 төркем инвалидлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Горшково авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- халыкның күпләп ял итү урыннарын (паркларны, скверларны, яр буен, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннарны) төзекләндерү һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү;

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү», карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар Җыенының нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Ленино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/,» Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: (httr://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге башлыгы С.Ю.Питеркина